ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноябрь 2020 ел № 15

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 17 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Балтач район башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2019 елның 12 августындагы 277 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 17 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертеп түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. Капиталь төзелеш объектын шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта );

1.2. Капиталь төзелеш объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында сүтелеп бетүе турында хәбәрнамәне урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru. рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Норма авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Мубаракшин